ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЫ

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАРГА ФОНЕТИКА

Методик кулланма

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАРГА ФОНЕТИКА

Методик кулланма

Казан
2024

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 нче елның 25 августында 730 нчы номерлы карары белән расланган “Татар халкының милли тәңгәллеген саклап калу” Татарстан Республикаксы дәүләт программасы кысаларында басыла

Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты; **Гыйләҗева Л.Г.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; **Фәттахова Р.Ф.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; **Хадиева Г.В.**, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы, **Вahапова Ә.Р.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы.

Хезмәт белем бирү оешмаларында эшләүче туган (татар) тел һәм әдәбият укытучыларына, мәктәп җитәкчеләренә, милли мәгариф хезмәткәрләренә тәкъдим ителә. Хезмәт татар тел белеменең «Фонетика» курсына карый. Туган (татар) тел һәм әдәбияты дәресләрендә татар теле фонетикасын үткәндә өстәмә куллану өчен тәкъдим ителә торган материалларны үз эченә ала.

Туган (татар) телен укытканда укучыларда компетенция булдыру

Яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартлары укучы шәхесенең үсешен төп максат итеп куйган системалы-эшчәнлекле якын килеп укытуны алгы планга куя. Бүгенге көн белем бирү системасы традицион рәвештә белем һәм күнекмәләр бирүдән баш тарта, Стандарт формулировкасы укучы ия булырга тиеш булган эшчәнлекнең реаль төрләрен күрсәтә.Белем алу нәтиҗәләренә таләпләр шәхескә кагылышлы, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләр рәвешендә формалаштырылган. Туган (татар) тел курсы гамәлдәге һәм яңартылган белем бирү стандартларына туры китерелеп, барлык сфераларда да аралашуны булдыру өчен кирәкле булган эшчәнлек төрләре тәкъдим итә: көнкүреш, социомәдәни, рәсми-эшлекле, шулай ук өйрәнелә торган телнең мәдәниятенә якынаю.

Туган телне өйрәнү барышы компетенцияләргә нигезләнә. Компетенция — латинчадан ирешү, тиешенчә ярашу, нигезләү мәгънәсен аңлата. Туган телдән белем бирүнең максаты — Федераль дәүләт белем стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә, лексик темаларга нигезләп, укучыларда коммуникатив (аралашу осталыгы), лингвистик, социомәдәни компетенцияләр формалаштыру.

Коммуникатив компетенция. Компетентлы белем бирүнең төп спецификасы кемдер тарафыннан тәкъдим ителгән “әзер белем” түгел, ә белемне укучы үзе этаплап эзләүгә, кабул итүгә нигезләнә. Даими рәвештә тикшеренү характерына ия булып, әлеге юл уку эшчәнлеген танып белү, үзләштерү предметы булып куя. Икенче төрле әйткәндә, компетентлы якын килү ул билгеле бер “катып калган” белемнәргә түгел, ә “укырга өйрәтергә” кирәклекне аңлата. Белем бирү эчтәлегеннән чыгып, түбәндәге конпетенцияләрне аерып чыгаралар: 1) төп яки предметара компетенцияләр (иң гомуми төшенчәләр); 2) гомумпредметлы (берничә предметка кагылышлы) 3) предмет компетенцияләре (бер предметка караган). Шулай итеп, татар теле өйрәтүдә компетентлы якын килүнең төп максаты — төрле яклы үсеш алган укучы шәхесен формалаштыру, аның теоретик фикер йөртүен, тел интуициясен һәм мөмкинлекләрен, аралашу һәм үз-үзеңне тоту культурасын үстерү. Федеральдәүләт белем бирү стандартында телгә өйрәтү курсының түбәндәге бурычлары билгеләнгән: коммуникатив, лингвистик һәм социомәдәникомпетенцияләрне формалаштыру. Матур, дөрес итеп сөйләм оештыру проблемасы хәзерге вакытта бик тә әһәмиятле. Бүгенге көн мәктәбе белемнәр кабул итеп кенә калмыйча, әлеге белемнәрне тормышта төрле ситуациягә карап файдалана, аралаша белгән һәм эчке культурасы булган укучылар әзерләргә тиеш.

Коммуникатив компетентлылыкка ирешү — социаль актив шәхес формалаштыруның мөһим шарты. Анык, грамматик яктан дөрес итеп сөйләшү, үз фикереңне ирекле интерпретациядә әйтү, эмоцияләреңне төрле интонация чаралары белән белдерә алу, сөйләм культурасын саклау һәм аралаша белү — һәрбер кеше өчен дә бик кирәк. Шуңа күрә укучыларның коммуникатив сәләтләрен үстерү белем бирүнең хәзерге этабында бик тә мөһим бурычларның берсе булып тора. Коммуникатив компетенция – теге яки бу телдә сөйләшүче шәхеснең иң мөһим характеристикасы. Коммуникатив компетенция гадәти тормышчан сөйләм эшчәнлегендә дә һәм махсус өйрәтү нәтиҗәсендә дә булдырыла. Улсөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә ия булуны, язма һәм сөйләм теле культурасының нигезләрен белүне, телне төрле сфераларда һәм аралашу ситуацияләрендә куллану күнекмәләрен күзаллый. Татар теле дәресләрендә тел белеменең тармаклары өйрәнелә. Шул ук вакытта укучы теорияне белү белән беррәттән, «ситуатив грамматика»ны да белергә тиеш, бу төр грамматика телне лексик берәмлек һәм аның билгеле бер сүзләр белән бәйләнешкә керүен билгели торган кагыйдәләр белән беррәттән, сөйләшүче һәм адресат белән мөнәсәбәт характерыннан, сөйләшү максатыннан һәм факторлардан чыгып та кулланууны тәэмин итә. Болар барысы бергә коммуникатив компетенцияне тәшкил итәләр. Коммуникатив компетенция биредә социомәдәни компетенциянең бер өлеше булып тора, шәхеснең гомуми гуманитар мәдәниятлелеген үстерүгә китерә.

«Фонетика» бүлеген үткәндә, укучыларны аралашырга, аралашу процессында яңа мәгълүмат алырга, белемнәрен ныгытырга, үз фикерләрен, фаразларын әйтергә, башкаларның фикерләрен тыңларга, анализларга өйрәтә торган биремнәр аша без дәрестә коммуникатив компетенция формалаштыра алабыз. Мәсәлән:

1. Илдар Юзеевның «Хатасыз ничек язарга?» шигырен укы.

Дәрестә — диктант. Хатасыз
Язарга ничек кенә?
Артта утырган Фәритнең
Тавышы ишетелә:
«Алло! Алло! Әни! Синме?
Үзең белмәсәң, эзлә!
Әйт тиз генә:
«И» ме, «е» ме «телефон» дигән сүздә?»

Фәриткә нинди киңәш бирер идең? Дөрес итеп язу өчен нишләргә кирәк?

4. Түбәндәге биремнәрнең берсен сайлап алып, үзең орфографик сүзлекчә төзе һәм сыйныфташларыңа тәкъдим итәргә әзерлән.

• Китапханәдән яки Интернеттан *(www.tatknigafund.ru)* Габдулла Тукайның «Су анасы» әкиятен тап һәм тексттан дөрес язылышларын истә калдырырга кирәкле сүзләрне генә алфавит тәртибендә дәфтәреңә күчереп яз.

• Дөрес язу кагыйдәләрен искә төшер. Бер кагыйдәне сайла һәм, шул кагыйдәгә караган сүзләрне туплап, сүзлекчә төзе. Сүзләрне дәреслектән, сүзлекләрдән, газета-журналлардан сайлап ал һәм алфавит тәртибендә яз.

38. С Текстны укы. Син кайсы ел фасылын яратасың? Ни өчен?

Кайбер кешеләр көзне яратып бетерми. «Әле яңгыр ява, әле, ялтырап, кояш чыга. Өстеңә нәрсә киеп чыгарга да аптырыйсың. Кырау төшә, кошлар китә, яфраклар коела, бик тә моңсу була», — диләр. Ә мин көзне дә яз белән җәйне яраткан кебек яратам. Көз бик матур ул. Юллардан ашлык төялгән машиналар чаба, бакчаларда алмалар, помидорлар пешә. Алтын көз — муллык көзе — җир өстенә канатын җәя.

Газиз Мөхәммәтшиннан

Хәзерге заман хикәя фигыльләрне табып, тартык һәм сузык авазларга таркатып яз.

Лингвистик компетенция. Лингвистик компетенция укучыларның сөйләм тәҗрибәсен аңлауны белдерә. Ул татар теленә кагылышлы төп теоретик материалны белүне үз эченә ала, лингвистик төшенчәләр комплексын үзләштерүне күзаллый. Лингвистик компетенция шулай ук татар теленең структур үзенчәлекләрен, телнең кеше тормышында әһәмитяле роль уйнавын аңларга, туган телгә ихтирам һәм мәхәббәт тәрбияләргә булыша. Лингвистик компетенция укуга һәм телне белүгә караган белем һәм күнекмәләрне булдыруны да күз алдында тота. Аңа, беренче чиратта, тану күнекмәләрен кертәләр: авазларны, хәрефләрне, сүзнең кисәкләрен, морфемаларны, сүз төркемнәрен һ.б. берсен икенчесеннән аера белү. Икенче төркем күнекмәләр – классификация ясый торган күнекмәләр: тел күренешләрен төркемнәргә бүлә белү күнекмәләре. Ниһаять, өченче төркем – аналитик күнекмәләр: фонетик,сүз ясалышы, морфологик, синтаксик, стилистик анализ ясау.

Лингвистик компетенция укучының танып белү культурасын, логик фикер йөртүен, иҗади фикерләвен, үзанализ, үзбәя күнекмәләрен

үзләштерүен тәэмин итә, шулай ук укучының үз сөйләм эшчәнлеген аңлау процессы буларак лингвистик рефлексия булдырырга ярдәм итә.

Социомәдәни компетенция. Мәдәният кешедән башка була алмый. Ул аны тел, тәрбия, тере аралашу аркылы үзләштерә. Туган як мәдәниятен тулысынча аңлау башка илләрнең мәдәнияте һәм телләре белән танышмыйча мөмкин түгел. Бүгенге көндә күпмәдәниятле, полилингвистик шәхесне формалаштыру актуальпроблемаларның берсе булып тора.

Яңартылган белем бирү стандартлары телне өйрәнүнең төп максатларының берсе итепсоциомәдәникомпетенцияләрне формалаштыруны алга куя, ул түбәндәге нигез булып торган моментларны күз алдында тота:

1) тел милли мәдәниятнең бер өлеше һәм нигезе булып тора;

2) телне өйрәнү – милли мәдәниятне өйрәнү дигәнне аңлата;

3) кешенең сөйләме, аның телгә мөнәсәбәте — ул шәхеснең рухи-әхлакый культурасы чагылышы булып тора;

4) аралашу чарасы буларак телне белү шәхеснең сөйләм культурасына, аралашу культурасына ия булуын күрсәтеп тора.

Шулай итеп, татар телен укытуда социомәдәникомпетенция укучының рухи-әхлакый үсеше аның милли үзаңы һәм гомумкешелек кыйммәтләр системасы формалашу өчен мөһим булган чара булып тора.

Хәзерге вакытта тел укыту практикасында яңа технологияләр, аерым алганда, татар телен укытуның дидактик-методик системаларын төзү белән бәйле технологияләр булдыру тенденцияләре күзәтелә. Гомуми компетенцияләрне үстерү буенча педагогик максатларның үзенчәлеге шунда ки, алар укытучының гамәлләре рәвешендә түгел, ә билгеле бер социаль тәҗрибәне үзләштерү процессында, аны алга җибәрү һәм үстерү күзлегеннән чыгып, укучы эшчәнлеге нәтиҗәләре күзлегеннән формалаша. Укытучы ни генә эшләсә дә, нәтиҗәдә, ул укучының үз эшчәнлеге белән мөстәкыйль идарә итү, субъект буларак үз-үзе белән идарә итү сәләтен формалаштыра һәм үстерергә ярдәм итә.Компетенция шәхеснең билгеле бер даирәгә караган предметлар һәм процесслар белән бәйле һәм аларга карата сыйфатлы продуктив эшчәнлек өчен кирәкле булган бер-берсенә бәйле сыйфатлары (белемнәре, осталыгы, күнекмәләре, эшчәнлек алымнары) җыелмасын үз эченә ала.

Димәк, укучы өчен компетенция — аның киләчәк образы, үзләштерү өчен ориентир булып тора. Шуңа бәйле рәвештә, белем бирүнең федераль стандартларында һәм татар теле программасының аңлатма язуында «компетенция» төшенчәсе барлыкка килде. Бу төшенчә аша татар телен укытуның гомумиләштерелгән структуралары билгеләнә.Әлеге документлар мәктәптә туган (татар) телен укыту өчен дә, аерым алганда тел, лингвистик,

коммуникатив һәм культурологик компетенцияләр формалаштыру өчен дә конкрет максатлар булган предмет компетенцияләрен билгеләделәр.

Гамәлдәге программаларда укучыларның тел компетенциясе дигәндә, әдәби тел нормалары нигезендә сүзләрне, аларның формаларын, синтаксик структураларны куллану, телнең синонимик структураларын әдәби тел нормаларына туры китереп файдалану, синонимия чараларын куллану, ахыр чиктә — уңышлы сөйләм эшчәнлеге шарты буларак, тел байлыгын белүе, аңлавы күрсәтелә. Лингвистик компетенция тел компетенциясе синонимы буларак кулланыла. Коммуникатив компетенция формалаштыру–озак һәм шактый катлаулы процесс. Татар телен укытуда фән курсының һәм баланың реаль сөйләм тәҗрибәсенең тәңгәллеге, тел турында белем алу процессы һәм телне үзләштерү процессы аеруча катлаулы.

Мәдәни аспект — теоретик нигезләмәләр, гамәли эшләнмәләр, эксперименталь тикшеренүләрдән торган хәзерге методикагың бик мөһим бер аспекты булып тора. Ул, бер яктан,укытучыга укучы белән мәдәният һәм тел арасында арадашчы булырга, икенче яктан, укучыларга халык мәдәниятенә якынаю, милли һәм гомумкешелек характерындагы төп кыйммәтләрне кабул итәргә, эмоциональ кичерергә һәм үзләштерергә мөмкинлек бирә.

Татар теле дәресләрендә фонетика курсын өйрәнгәндә компетенцияләрне булдыру

Фонетиканы өйрәнгәндә компетентлы якын килү

Татар телен өйрәнгәндә компетентлы якын килү тел белеменең төрле тармакларын — фонетиканы, лексикологияне, сүз ясалышын, морфологияне, синтаксисны өйрәнгәндә тормышка ашырыла. Телне белү һәм сөйләшә белү фонетиканы һәм аның базасындагы фонологик ситеманы өйрәнмичә мөмкин түгел. Татар телен өйрәнгәндә, телнең сүзлек составын, сүз ясалышы һәм грамматик төзелешен үзләштерү белән беррәттән,аның фонетик һәм фонологик системасын өйрәнү дә бик мөһим. Биредә сөйләм авазларының сүзләрдә һәм сүзтезмәләрдә билгеле бер урында килүләренә карап, функциональ үзгәрешләргә тиешле игътибар бирелергә тиеш. Ә фонетика буенча эш интонация өстендә эшләү белән өзлексез алып барыла. Моның белән бәйле рәвештә, укучылар программа нигезендә сөйләм авазлары системасын,сүз басымын; интонациянеүзләштерергә тиешләр.Бу таләпләрне тормышка ашыру өчен укытучыга фонетика курсын үткәндә һәм шулай ук гомумән, уку елы дәвамында укучыларның татар теленең фонетик закончалыкларын үзләштерү өчен эш системасын җентекләп планлаштыру кирәк.

Лингвистикада авазлар өч яктан чыгып каралалар: физиологик (артикуляция), акустик (ишетеп аңга алу), функциональ(фонологик). Барлык өч аспект та мәктәп курсында чагылыш таба. Татар теле фонетикасына өйрәтү методикасы бурычы — морфемалар, сүзләр, җөмләләр составында аваз тамгаларының һәм нормаларының үзләштерелүләре. Фонетиканы өйрәнгәндә функциональ якын килү фонемаларның мәгънә аеру функцияләренә аерым игътибар бирүне сорый. Һәрбер аваз да фонема булмый.

Өйрәнү предметы буларак татар теленең фонетик системасы

Фонетиканы өйрәнү теоретик һәм практик яктан зур әһәмияткә ия. Фонетиканы өйрәнмичә, телнең лексик һәм грамматик төзелешен өйрәнү мөмкин түгел.

Фонетика — телнең аваз ягын өйрәнү предметы булган бердәнбер дисциплина. Калган дисциплиналар морфемаларның, сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләрнең структур-мәгънәви ягы үзенчәлегенә игътибар итәләр.

Фонетиканы өйрәнүнең төп максаты — укучыларга телнең аваз ягын ачу, аның лексикология, грамматика белән булган бәйләнешен күрсәтү. Икенче төрле әйткәндә, фонетика гамәли бурычларны хәл итә, ягъни укучыларның татар телендә дөрес әйтү күнекмәләрен үстерә. Коммуникатив функция дөрес әйтелешнең мәгънәсен билгели, чөнки әйтелә торган авазларның бозылуы, басымның дөрес куелмавы яки интонациянең дөрес кулланылмавы фикерне дөрес аңламауга китерергә мөмкин.

Фонетика курсының танып белү максаты — укучыларга татар теленең авазлар системасы турында күзаллау тудыру, авазларны һәм хәрефләрне бутау күренешен булдырмау, әдәби әйтелеш нормалары белән таныштыру. Гамәли максаты — фонетик күренешләр формалаштыру, татар теленең авазларын тану, төркемләү, сүзнең аваз составына анализ ясау, орфограммаларны белү. Үстерелешле максаты әйтү-ишетү культурасын булдырудан гыйбарәт. Тәрбияви максат исә сөйләм культурасын тәрбияләүне күз алдында тота.

5 нче сыйныфта «Фонетика» тармагын өйрәнгәндә, укучыларда лингвистик, коммуникатив компетенцияләр булдырала. Предмет нәтиҗәләргә түбәндәге күнекмәләр керә: авазларны аерып чыгара белү, аларның мәгънә аеру функцияләрен билгеләү, фонетик процессларны билгеләү, авазларга характеристика бирү, сүзләрне иҗекләргә һәм юлдан-юлга күчерү өчен бүлү, авазлар һәм хәрефләр арасында тәңгәллек булдыру, фонетик анализ ясау, дөрес сөйләү нормаларына ия булу. Фонетиканы өйрәнү нәтиҗәсендә укучылар аваз һәм мәгънә арасында, сүзнең аваз тышчасының лексик һәм грамматик күренешләрбелән аерылмас бәйләнештә булуын аңларга тиешләр.

Фонетика тел төзелешенең түбәндәге элементларын өйрәнү белән шөгыльләнә: тавыш, аларның төрле акустик үзлекләре, иҗек төзелеше, сүз басымы, паузалар, ритм, интонация. Әмма аны өйрәнүнең төп предметы булып өч аспектта — акустик, физиологик, функциональ аспектта карала торган тавыш тора. Өйрәнүнең барлык өч аспекты да мәктәптә фонетика курсында чагылыш тапкан.

Фонетиканы өйрәнү процессында укучылар теоретик белемнәрнең билгеле бер суммасын гына түгел, шулай ук түбәндәге мөһим гамәли күнекмәләрне дә үзләштерергә тиеш:

- яңгырау һәм саңгырау тартыкларны ишетә белү;
- сүздә кирәкле тартыкны аерып чыгара һәм дөрес әйтә белү;
- сүздәге басымның урынын билгели белү;
- яңгырашы буенча охшаш сүзләрнең аваз составын чагыштыра белү, аларның яңгырашындагы аермалыкларның сәбәбен ачыклау;
- авазлар һәм хәрефләрмөнәсәбәтен дөрес аңлатып, сүзләрне фонетик-график яктан тикшерә белү.

«Фонетика» бүлеген өйрәткәндә кулланыла торган принциплар, алымнар һәм методлар

Мәктәптә «Фонетика» бүлеген өйрәнүнең төп юнәлешләре

Фонетиканы өйрәнүгә багышланган дәресләрдә укытучы укучыларны сөйләм авазларын ишетеп аңлауга өйрәтергә һәм аларны язма рәвештә билгели белергә өйрәтергә тиеш. Моннан тыш, авазларны һәм хәрефләрне системалы рәвештә максатчан чагыштыру да алып барыла. Бу принципларны тормышка ашыру процессы укучыларда сөйләм ишетү сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

Фонетиканы өйрәнү авазларны әйтелеш нормаларына, төрле бүлекләрдә авазлар тезмәсенә өйрәтү белән, сүзләр, сүздә басым кую нормалары белән бәйле булырга тиеш. Әлеге принципны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып, укучыларда орфоэпик белем һәм күнекмәләр формалашу тора.

Орфографияне уңышлы үзләштерү өчен, укучыларда база төшенчәләрен формалаштыру мөһим, мәсәлән, сузыклар – басымлы һәм басымсыз, яңгырау һәм саңгырау тартыкларга бүленә, һ.б. Нәтиҗәдә, фонетиканы өйрәнүдә укучыларны орфографияне өйрәнүгә әзерләү кебек практик юнәлеш тормышка ашырылачак.

Фонетика бүлеген өйрәнгәндә төрле алымнар һәм укыту методлары кулланыла. Өйрәнелә торган материалның характеры аларны сайлауны һәм куллануны билгели. Укучыларны телнең аваз системасы һәм аның сыйфатлары белән таныштырганда, укытучының аңлатуы максатка ярашлы. Сөйләмдә авазларның ролен һәм аларның акустик-физиологик үзлекләрен өйрәнгәндә, шулай ук язуда авазларны билгеләгәндә, гадәттә, әңгәмәне, күзәтү методларын, тел күренешләрен проблемалы укыту элементлары белән анализлауны кулланалар. Әңгәмә методын фонетика һәм графика өйрәтүнең барлык этапларында да куллану уңышлы. Укучыларга яңа төшенчәләрне аңлатканда, укытучы эвристик әңгәмә уздыра, аның асылы сорауларны дөрес куеп укучыларны дөрес нәтиҗәләр формалаштыруга этәрүдән гыйбарәт.

Фонетиканы өйрәнгәндә, сөйләмнең аваз ягын күзәтү, әйтелештә куллану, фонетик яктан тикшерү, билгеле бер авазлы сүзләрне төркемләү. Күзәтү методын оештырып, укытучы тавыш белән хәреф принцибын исәпкә алырга тиеш.

Укытучыга сөйләмгә тиешле игътибар юнәлттерү бик әһәмиятле. Фонетиканы өйрәнү белән кызыксынуны уен биремнәрен куллану ярдәмендә тудырырга мөмкин. Бу алымнар укучыларны активлаштыра, хәрефне һәм авазны аера белергә ярдәм итә. Методик яктан дөрес уйланылган уен,

беренчедән, укучыда туган телгә карата мәңәббәт тәрбияли, сөйләм күнекмәләрен үстерергә булыша, сөйләм эшчәнлеген табигый нормаларга якынайта, икенчедән, белем бирүнең коммуникатив юнәлеше таләпләренә җавап бирә. Уеннар вакытында укучыларның белем һәм күнекмәләре камилләшә. Аларда бердәмлек, бер-берсенә ярдәм итү теләге туа. Мәсәлән, фонетиканы өйрәнгәндә, «К хәрефенә башланган кош атамалары яз», «Йорт хайваннары һәм кош атамаларындагы сузыкларны яз», «Иҗекләрне сүзләр килеп чыгарлык итеп тоташтыр», «Сүзләргә хәрефләр өстәп, яңа сүзләр яса»кебек уеннарны уйнату методик яктан бик файдалы булачак.

Дәресләрдә төрле ысуллар һәм алымнар куллану күрсәтмәлелек һәм укытуның техник чаралары белән бергә алып барылырга тиеш. Аудиоязмалар куллану авазларның дөрес артикуляциясен үзләштерергә һәм орфоэпик тайпылышларны җиңәргә ярдәм итә. Алар балаларда эстетик зәвык тәрбияләр һәм фонематик ишетү сәләтен үстерәләр. Аудиоязмаларны тыңлау дөрес әйтелешнең нәтиҗәле чарасы булып тора, ул шулай ук дәресләрдә лексика, морфология һәм синтаксис дәресләрендә кулланыла ала.

Белем бирү үзәгендә сөйләмнең аваз ягы булуын исәпкә алып, әлеге дәресләрдә телдән күнегүләргә зур урын бирелә. Анализланырга тиешле текст яки сүз кычкырып әйтелә һәм укыла. Биремнәрнең күпчелеге авазларның ясалу үзенчәлеген, авазларны әйткәндә сөйләм органнарыэшчәнлеген, авазларның функцияләрен һәм аларның ярашуларын күзәтү нигезендә төзелә. Фонетик күренешләрне анализлауга юнәлдерелгән күнегүләр индуктив метод ярдәмендә башкарыла. Шул ук вакытта, укучылар телдән сөйләмнең беренчел, ә язма сөйләмнең икенчел булуын ассызыкласын өчен, аваздан хәрефкә булган эзлеклелекне сакларга кирәк. Бурычларның мондый эзлеклелеге программа бүлеген өйрәнүнең эзлеклелеге белән тәэмин ителә: башта фонетика, аннары графика һәм орфоэпия үтелә.

Фонетик күнегүләр системасына укучыларга дөрес дикция ясарга, бәйләнешле текстларны сәнгатьле укырга, сүзләрне дөрес ассызыкларга, логик басым ясарга, орфоэпик нормаларны саклап, үз фикерләрен белдерергә ярдәм итә торган иҗади биремнәрне кертергә мөмкин. Мондый күнегүләр өчен материал булып төрле эчтәлектәге текстлар була ала, чөнки аларда фонемаларның функциясе ачыла, сөйләм темпы, тавыш көче, мәктәп стилистикасын өйрәнү предметы булган фонетиканың сәнгатьле чаралары күрсәтелә. Күнегүләр сайлап алганда, аерым авазларның һәм сүзләрнең әйтелешендәге җитешсезлекләргә игътибар биреп, укучылар сөйләменең диалекталь үзенчәлекләрен дә исәпкә алырга кирәк. Татар теленең аваз һәм график системасын өйрәнгәндә, фонетика дәресләрендә орфоэпик нормаларны үзләштергәндә, укучылар теоретик мәгълүматларның билгеле

бер суммасына һәм күп кенә мөһим гамәли белем һәм күнекмәләргә ия булалар:

- яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аера белү;
- сүздә кирәкле тартыкны аерып күрсәтә белү һәм аны дөрес әйтү;
- сүздәге басымның урынын билгели белү;
- сүзләрне ачык итеп әйтә белү, әйтелешнең дөреслеген күзәтү;
- сөйләм теленең байлыгына һәм аһәңлелегенә ирешү.

«Фонетика» курсын өйрәнү принциплары

Фонетика дәресләрендә экстралингвистик принцип, исемнәре бер-ике фонема яки аларның тәртибе белән аерылып торган предметларның рәсемнәрен куллану мөмкинлегенә нигезләнә.

Функциональ принцип фонемалар белән бер-берсеннән аерылып торган сүзләрнең аваз составларын күзәтү барышында тормышка ашырыла.

Норматив-стилистик принцип укучыларны әйтелеш нормаларының саклануына этәрә (акцентологик, орфоэпик, интонацион).

Тарихи принцип фактларны чагыштыру процессында кулланыла.

Сөйләмнең аваз ягын өйрәнүнең шәхси методик принциплары ишетеп аңга алу, укучыларга сүзләрнең корпусын тәшкил итүче авазларны аеру мөмкинлеген бирә, алар авазларны аеру, ишетү, редукцияләү һәм таркату процессларын исәпкә алалар;

- авазны тикшерепкарау лексик, сүз ясалышы яки грамматик мәгънәсен билгеләү максатында сүзнең әһәмиятле өлешләрен аерып карауга китерә;

- авазларны һәм хәрефләрне чагыштыру укучыларга графика һәм орфография кагыйдәләре ярдәмендә сүзнең аваз составын өйрәнү принцибын аңларга ярдәм итә.

«Фонетика» курсын үткәндә кулланыла торган да күнегүләр системасы

Белемнәрне ныгыту этабында төрле характердагы күнегүләр һәм фонетик тикшерү үткәрелә. Гадәттә, фонетик күнекмәләрне формалаштыруга юнәлдерелгән 5 төркем күнегүне аерып чыгаралар.

Мисалларны аерым бер дәреслек нигезендә карап китик (Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5 нче сыйныф / Р.Р.Шәмсетдинова, Г.К.Һадиева, Г.В.Һадиева. — Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2017. — 178 б.).

Беренче төркем күнегүләр сүзләрдә авазларны аера белү күнекмәләрен формалаштыруга юнәлтелә. Мәсәлән,

67. **Сүзләрдәге сузык авазларга характеристика бир.**

дәрес, көз, салкын

Үрнәк: ***[ә] — нечкә сузык аваз, иренләшмәгән.***

73. Түбәндәге тәҗрибәне үткәреп, [б]—[п], [д]—[т] авазларының яңгыраумы яки саңгыраумы икәнен әйт. Нәтиҗә яса.

Тартык авазның яңгырау яки саңгырау икәнен бик җиңел белеп була. Учыңны бугазга куеп, бирелгән тартык авазларны әйтеп кара. Яңгырау авазларны әйткәндә, тавыш ярыларының калтыравын, тибрәнешен тоясың, ә саңгырау авазларны әйткәндә, тавыш ярылары калтырамый.

Икенче төркем күнегүләр авазларның мәгънә аеру ролен билгеләүгә карый (мәсәлән, кул һәм күл сүзләрен нинди аваз ярдәмендә аерылып тора.)

39. Нокталар урынына тиешле хәрефләр куеп, яңа сүзләр ясап яз. Бу сүзләрнең аваз составында нинди уртаклык һәм аермалык бар?

б..л, б..л, б..л, б..л, б..л

т..н, т..н, т..н, т..н, т..н

ка..ак, ка..ак, ка..ак

..арак, ..арак

Берничә сүз белән телдән җөмләләр төзе.

44. Сузык авазларының калынлыгы яки нечкәлеге белән генә аерылган сүзләр уйлап яз.

Үрнәк: *бар — бәр, ...*

45. Татар сүзләре белән рус сүзләрен чагыштырып укы. Сузыкларның әйтелешенә игътибар ит.

он — он	сын — сын
тот — тот	тире — тире
сыр — сыр	бор — бор

80. Сүзләрнең беренче тартык авазын яңгырау яки саңгырау парына үзгәртеп әйт. Сүзнең аваз составы үзгәрәме? Бер пардан торган сүзләр белән ике җөмлә уйлап яз.

кер — *гер*	зал — ...
бар — ...	җәй — ...
Вил — ...	дага — ...
гөл — ...	җир — ...
дала — ...	сат — ...

Өченче төркем күнегүләр сүзне иҗекләргә һәм юлдан-юлга күчерү күнекмәләрен булдыруга, сүзләрне иҗекләргә бүлеп әйтү, язуда иҗекләрне сызыкча аша күрсәтү, сүзне юлдан-юлга күчерү мөмкинлекләрен күрсәтүгә юнәлдерелә.

131. Укы, текстның исемен аңлат. Сүзләрне иҗекләргә бүлеп яз. Сузык авазлар саны белән иҗекләр санын чагыштыр.

КОРЫ ЯҢГЫР

Коры яңгыр ява торган җирләр дә бар. Барлык чүлләрдә дә бик кызу һәм коры һава. Анда ява башлаган **яңгыр** җиргә төшеп җиткәнче үк парга әйләнә. Тамчылар, төшсәләр дә, кешенең башына кадәр генә **төшеп** җитәләр. Чүл яңгыры астыннан коры чыгып була.

«Салават күпере» журналыннан

138. С Укы. Текстның төп фикерен әйт һәм исем бир. Һәр иҗек калыбына (С, ТС, СТ, ТСТ, СТТ, ТСТТ) икешәр мисал табып яз. Кайсы иҗек калыплары еш кулланыла? Нәтиҗә яса.

Әниләрнең иң матуры — минем әнкәй. Бу уемны мин Нәҗип белән Рамилгә дә әйттем.

— Минем әни матуррак! — диде Рамил җавабында.

Нәҗип тә бәхәсләшә:

— Иң матуры — минем әни! — ди.

Бәхәсләшә торгач, ул көнне без тарткалаша башладык, сугыша яздык. Ярый әле шунда, безне эзләп, су буена әниләребез килде. Аларның иң матуры минем әнкәй иде. Аның күзләре яшел иде. Ул чакта мин шуны да күрдем: Нәҗипнең әнисе — зәңгәр күзле, Рамилнең әнисе кара күзле икән.

Безнең әниләребез дә дуслар. Алар эшкә бергә йөриләр.

Рөстәм Мингалимнән

145. Түбәндәге иҗек калыпларына туры килә торган сүзләр уйла һәм аларны, юлдан-юлга күчерерлек итеп, иҗекләргә таркатып яз.

С, С-ТС, С-ТС-ТСТ, ТС-ТС-ТСТ, ТСТ-ТСТ, СТТ-ТС, ТТСТ-ТСТ

Дүртенче төркем күнегүләр акцент ясау күнекмәләренә карый: сүзгә басым кую, күчереп язганда сүзнең басымын күрсәтү, сүзнеңбасымын күрсәтеп язу, сүзнең басымын үзгәртеп язу (мәсәлән, бала – балалар – балаларның), басым соңгы иҗеккә төшмәгән очракларны билгеләү (мәсәлән, алынма сүзләр, сорау кисәкчәсе, билгесезлек, билгеләү, сорау алмашлыклары). Мәсәлән:

150. Җөмләләрне укы, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең басымын билгелә, сорау куй һәм нинди сүз төркеменә керүен әйт.

Әни **алма** бирде. Син бу дәфтәрне **алма**. Диван **җәймәбез** төрле төстә булды. Бу эскәтерне **җәймә**. Урманда **карама** агачлары үсә. Син бу якка **карама**. Елга аша **басма** салдылар. Син бу җиргә **басма**. Елгада су **кими**. Ул бүреген **кими**. Кибеттән дөге **ярмасы** алып кайт. Утынны **ярма**.

151. Төркемләп бирелгән сүзләрнең басымы кайсы иҗеккә төшүен әйт. Төркемдәге сүзләрне нинди охшашлык берләштерә?

1. Сөйлә, уйла, эшләгез, утырыгыз. 2. Килгәнче, алганчы, кайтканчы. 3. Ятламаган, үтәмәде, килмәгез. 4. Көлдеңме? Кабатладыңмы? Язамы? 5. Укыйсың, беләбез, ябасыз. 6. Сөйләшкәнмен, әйткәнбез, барачаксыз, алачакмын.

Татар телендәге сүз басымы түбәндәге очракларда **соңгы иҗеккә төшмәскә мөмкин:**

1. **II зат боерык фигыльләрдә** басым беренче иҗектә була: *ýкы! Я́зыгыз!*
2. **Фигыльдә юклык кушымчасына (-ма/-мә)** басым төшми, басым аннан алдагы иҗеккә төшә: *кýрмәде, ташлáмагыз.*
3. **-мы/-ме сорау кисәкчәсе** кушымчасы басымны үзенә алмый: *күрдéңме? Алдыңмы?*
4. **Хәзерге заман хикәя фигыльләрдә** басым зат-сан кушымчасы алдына төшә: *китáсең, килáсез.*
5. **-ган/гән, -кан/-кән** кушымчалы **үткән заман** хикәя фигыльләрдә һәм **-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк** кушымчалы **киләчәк заман** хикәя фигыльләрдә басым зат-сан кушымчалары алдына төшә: *эшләгáнмен, кайтачáксыз.*
6. Кайбер **күрсәтү** һәм **сорау алмашлыкларында** басым беренче иҗеккә төшә: *мóндый, нáрсәдән.*
7. **-дай/-дәй, -тай/-тәй, -ча/-чә** кушымчалары үзләренә басым алмый: *төлкéдәй, татáрча.*

Бишенчетөркем күнегүләрсүзнең аваз составын билгеләүгә юнәлдерелә: сүзләрдә авазларны әйтү, сүзгә фонетик анализ ясау.

62. Сүзләрне укы. Аларның әйтелеше белән язылышы арасында аерма бармы? Сүзләрнең транскрипциясен яз, нәтиҗә яса.

Үрнәк: *[болот]*, ...

болыт, төлке, төзелеш, гомер, тормыш

90. Сүзләрне укы. Үрнәк буенча тикшереп, нәтиҗә яса.

Үрнәк: *у[къ]учы.*

укучы	күзлек	реклама
кол	мәктәп	вагон
горур	гөлчәчәк	картина
сагыныч	дөге	корабль

209. Текстны укы. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә фонетик анализ яса.

Дөньяда иң зур кош — Африкада яшәүче **тәвә** кошы.

Аның **биеклеге** — өч метрга, ә **авырлыгы** 90 килограммга җитә. Тәвә кошлары очмый, ләкин бик яхшы **йөгерәләр**. Чүлдә аларны ат белән куып җитү дә җиңел түгел. Тәвә **кошларының** йомыркасы бик зур — **тәлинкә** кадәр, ә авырлыгы бер килограммнан артыграк.

Вакытлы матбугаттан

Шуңа бәйле рәвештә фонетикадан күнегүләр системасы телдән һәм язма эш төрләрен дә үз эченә ала.

1. **Телдән күнегүләр**. Мондый күнегүләрне сүзнең аваз составын билгеләргә кирәк булганда (сүзләрдә авазларны әйтү; сүзләрне аерып торган авазларны атау), алфавитны өйрәнгәндә (сүзләрне алфавит буенча урнаштыру) үткәрергә кирәк. Алар әйтелеш өстендә эшләгәндә бигрәк тә актуаль. Телдән күнегүләр орфоэпик нормаларны үтәү һәм сөйләмне ишетә белү күнекмәләрен үстерүгә юнәлтереләләр.Мондый төр күнегүләр белән укучылар логик сәнгатьлелекнең интонацион чаралары белән (логик басым, пауза, тон, темп) танышалар. Укучының текстны укуы һәрвакытта да аның интонацияне, темпны, тембрны дөрес сайлаганын аңлату һәм аңа карата коллектив рәвештә анализ ясау белән бергә алып барыла. Башта эш бер яки ике элемент өстендә генә үткәрелә, алга таба исә эш комплексны алып барылырга мөмкин.

158. Түбәндәге текстны тиешле интонация белән укы. Әйтү максаты буенча җөмләләрнең төрләрен билгелә.

Күктә әйтерсең көмеш кыңгыраулар чылтырый. Ничәү соң алар? Бары бер тургай! Әнә зәңгәр күктә тирбәлә. Ә җыры нинди! Шушы кечкенә кош сихри моңы белән ничек күңелне күтәрә икән? Иртә таңнан көне буе бертуктаусыз очарга да, җырларга да күпме көч кирәктер?!

Фоат Садриевтан

2. **Фонетик-график күнегүләр**. Алар авазлар һәм хәрефләрне аеру өчен кулланыла:

-авазларның хәрефләрен атау,

- конкрет хәрефләрнең аваз ягын билгеләү,

- аваз белән хәреф туры килми торган очракларны билгеләү.

154. Сүзләрдә *[ы],[э]* авазларының әйтелешенә игътибар итеп укы. Әйтелеш белән язылыш арасында нинди аерма бар? Сүзләрне күчереп яз, басымын билгелә.

[сәңәл] — [сәңләсә], [гъөмөр] — [гъөмрө], [исәм] — [исмә], [борон] — [борно], [күңәл] — [күңлә]

122. Сүзләрне дөрес әйтеп укы. Бу сүзләрне хәрефләр белән яз. *[м]* авазы урынына нинди хәреф яздың?

[умбиш], [умбәр], [көмбагъыш], [көмбатыш], [төмбойокъ]

3. **Сүзгә фонетик анализ ясау.** Анализның бу төре фонетиканыөйрәтү методикасында мөһим алымнарның берсе булып тора. Ул фонетика тармагы буенча булган белемнәрне кабатларга, ныгытырга, гомумиләштерергә ярдәм итә. Анализ өчен, нигездә, язылышыәйтелешенә (яки әйтелеше язылышына) туры килмәгән, бер хәрефнең ике аваз белдерү очраклары (мәсәлән, яз, елга, юлбарыс, табиб, сәгать, дөнья, каләм, һ.б.), төрле фонетикчолганышта иҗек һәм ике сүз чигендә барлыкка килгән авазчиратлашулары булган сүзләр (мәсәлән, сеңелем, бәрәңге, һ.б.) алына. Шулай ук басым төрлечә төшү сәбәпле, мәгънә буталышыкитереп чыгару мөмкинлеге булган сүзләрне (мәсәлән, алма, алма; ярма, ярма; бүлмә, бүлмә, һ.б.) дә алырга ярый. Мондый сүзләр, кагыйдә буларак,мәгънәсе дөрес аңлашылсын өчен, микротекст — җөмлә эчендә бирелә.

Фонетик анализ — ул белем бирү алымы гына түгел, ныгыту, гомумиләштерү һәм фонетика курсы буенча булган белемнәрне кабатлау чарасы да булып тора.

Сүзгә фонетик анализ ясау тәртибе

1. Сүз квадрат җәяләр эчендә иҗекләргә бүлеп языла, аларның ачык һәм ябык икәнлеге күрсәтелә.
2. Басымның кайсы иҗеккә төшүе күрсәтелә.
3. Авазлар, хәрефләр һәм аларның саны билгеләнә.
4. Сузык авазларның калынлыгы яки нечкәлеге, иренләшкән яки иренләшмәгән булуы билгеләнә; сингармонизмның рәт яки ирен гармониясенә буйсыну-буйсынмавы күрсәтелә.
5. Тартык авазларның ясалу урыны, яңгырау яки саңгырау (парлы яки парсыз), авыз яки борын авазы булуы; тартык авазларның чиратлашуы ачыклана.
6. Сүзләрнең әйтелеше белән язылышы, авазлар һәм хәрефләрнең туры килү-килмәве әйтелә.

Телдән тикшерү үрнәге

сурәт

Сурәт сүзе ике иҗектән тора. Беренче иҗек ачык, икенче иҗек ябык. Басым икенче иҗеккә төшә. Сүздә 5 аваз бар: [с], [ү], [р], [ә], [т], 5 хәреф бар: «эс», «у», «эр», «ә», «тэ».

Сузык авазлар:

[ү] – нечкә, иренләшкән.

[ә] – нечкә, иренләшмәгән.

Тартык авазлар:

[с] – саңгырау, яңгырау пары – [з], тел алды, авыз авазы.

[р] – яңгырау, парсыз, тел алды, авыз авазы.

[т] – саңгырау, яңгырау пары – [д], тел алды, авыз авазы.

Сүз сингармонизмга буйсына. Сүзнең әйтелеше белән язылышы туры килми. Нечкә [ү] авазы урынына **у** хәрефе язылган.

Язмача тикшерү тәртибе

Сурәт[сү-рәт], ике иҗек; 5 аваз, 5 хәреф.

[с] – саңгырау, яңгырау пары – [з], тел алды, авыз авазы.

[ү] – нечкә, иренләшкән.

[р] – яңгырау, парсыз, тел алды, авыз авазы.

[ә] – нечкә, иренләшмәгән.

[т] – саңгырау, яңгырау пары – [д], тел алды, авыз авазы.

Сүз сингармонизмга буйсына.

Фонетик анализ фонетика курсын тәмамлап бетергәч тә, алдагы этапны (лексикология, морфология, синтаксис һәм шулай ук текстны уку процессында да) үткәндә дә үткәрелә. Укучы алдында язылган сүз булмаса, фонетик анализны шулай ук телдән дә үткәрергә була, шул рәвешле алга таба язылыш белән әйтелеш арасында тәңгәлләштерү табарга мөмкин булачак. Мондый анализ укучыларның ишетеп аңга алуларын үстерә, авазларны ишетеп аера белү, язылыш белән әйтелеш арасындагы тәңгәллекне әйтергә өйрәтә, ә бу исә, үз чиратында грамоталы язуга ярдәм итәчәк.

Компетенция булдыруга юнәлдерелгән биремнәр

Россиянең белем бирү системасын яңарту концепциясендә укучыларның белем һәм күнекмә үзләштерү генә түгел, ә шәхеснең һәм аның универсаль мөмкинлекләре, сәләтенә нигезләнгән сыйфатлы белем бирүнең төп компетенцияләрен формалаштыру алгы планга чыга. Димәк, укытучыга мәктәп диварларында ук укучы “мөстәкыйль эшчәнлек тәҗрибәсе һәм шәхси җаваплылык”ка ия булырга ярдәм итә торган шартлар тудыру максаты һәм ихтыяҗы туа. Бу исә укытуның уку-дисциплинар төреннән укучылар үзләре мөстәкыйль рәвештә карар кабул итәргә һәм нәтиҗәләрне алдан фаразлый ала торган практик-ориентлашкан төренә күчүнең кирәклеген ассызыклый.

Укучы нинди булырга тиеш соң? Бүгенге көн укучысы кызыксынучан, дөньяны актив танып белүче, укый белү күнекмәләре нигезләренә ия булган, ягъни компетентлы булырга тиеш. Укытучы эшчәнлегенең максаты да белем һәм күнекмәләрнең системасын булдыруга гына кайтып калмыйча, ә укучының интеллектуаль, хокукый, мәгълүмати һәм башка сфераларында төп компетенцияләр булдыру һәм аларны алга таба үстерү өчен шартлар тудырудан гыйбарәт. Бүгенге көндә белем бирү нәтиҗәсе итеп ятланган белемнәр суммасы түгел, ә төрле проблемалы ситуациядә эш итә белү күнекмәләренә ия булу санала.

Үз дәресендә компетентлы якын килүне тормышка ашырырга теләгән теләсә кайсы укытучыга төп кыенлык булып, тиешле технологик инструмент — белем бирүнең методлары, формалары, биремнәр һәм күнегүләр сайлауда тора. Тормышка нигезләнгән һәм укучыны җавап эзләүгә этәрә торган биремнәр генә компетентлы бирем булып санала ала. Тәкъдим ителгән бирем балага шәхси әһәмиятле булырга тиеш, шул вакытта гына ул аңа кызыклы була алачак һәм укытучының максатлары да укучыга ят булмас. Компетенция булдыруга юнәлдерелгән биремнәр дәрескә традицион якын килүне үзгәртәләр. Алар укучының белем һәм күнекмәләренә нигезләнәләр, ләкин тупланган белемнең практик эшчәнлектә кулланылышын таләп итәләр, чөнки компетенция булдыруга юнәлдерелгән биремнәр билгеләнелеше укучыларны тормышчан бурычларны чишүгә “чумдыру”дан гыйбарәт. Компетенция булдыруга юнәлдерелгән биремнәр, беренчедән, эшчәнлекле биремнәр, икенчедән, практик, тормышчан ситуацияне модельләштерәләр, өченчедән, алар укучылар өчен актуаль булган материал өстендә төзеләләр.

Уку материалын үзләштергәндә, укучыларның төрле төрдәге эшчәнлек үтәүләре бик мөһим, ләкин бүгенге көндә әле мондый типтагы әзер күнегүләр аз һәм шунлыктан укытучының үзенә билгеле бер конкрет дәрескә компетенция булдыруга юнәлдерелгән биремнәр төзү ихтыяҗы килеп баса. Биремнәрнең компетенция булдыруга юнәлдерелгән булуын ничек билгеләп

була соң? Беренчедән, ул — эшчәнлекле була. Икенчедән, ул практик, тормышчан ситуацияне модельләштерә. Өченчедән, биремнәр укучылар өчен актуаль булган материал өстендә төзеләләр. Дүртенчедән, аның билгеле бер структурасы бар:

- стимул, укучыларны бирем контекстына алып кереп китәргә, башкарырга мотивлаштырырга ярдәм итә,
- бирем формулировкасы, укучының биремне уңышлы башкарып чыгу өчен кирәкле булган эшчәнлегенә ишарә итә,
- чыганак, укучының биремне уңышлы үтәр өчен кирәкле булган мәгълүматны үз эченә ала,
- тикшерү инструменты (ачкыч), нәтиҗәне бәяләү критерийләрен билгели.

Компетенция булдыруга юнәлдерелгән фонетик биремнәр укучыларда стимулдан кирәкле булган мәгълүматны аңга алу, биремнең иң отышлы булган чишү ысулын сайлап алу, мөстәкыйль рәвештә танып белү максатын аерып чыгару һәм формалаштыру, шулай ук фикер йөртүнең эзлекле чылбырын булдыру һәм анализ ясау, гипотезалар чыгару һәм аны нигезләү кебек күнекмәләрне булдыруга юнәлдереләләр. Болар барысы да укучыга “Фонетика” курсын уңышлы үзләштерергә ярдәм итә. Компетентлы оритентлашкан биремнәр татар телен өйрәнүгә мотивацияне үстерүдә бер ысул булып торалар,чөнки

- беренчедән, алар өстендә эшләгәндә укучы бирем башкаруга башкача якын килә,
- икенчедән, компетентлы оритентлашкан биремнәр башка төр эшчәнлек ысуллары таләп итә,
- өченчедән, өйрәнелә торган материалның өстәмә мөмкинлекләрен исәпкә алып, эшчәнлекне үзләштерү һәм куллану өчен белем бирү ситуацияләрен модельләштерергә мөмкинлек бирәләр;
- дүртенчедән, укучыларның фикер йөртүләрен үстерергә, материалны яхшырак үзләштерергә һәм предметка карата булган мөнәсәбәтен үзгәртергә ярдәм итә.

Компетенция булдыруга юнәлдерелгән биремнәр өстендә эшләгәндә, укучылар мөстәкыйль рәвештә формалаштырылган нигезләмәләре буенча башкарыла торган эшнең максатларын аңлап, мәгълүмат ала белергә, тәкъдим ителгән структура кысаларында мәгълүматны системага салырга, үз фикерләрен дәлилли белергә өйрәнәләр. Мондый төр биремнәр укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеген оештыру мөмкинлекләрен киңәйтәләр, укучының өйрәнелә торган тема, аның төп лингвистик компетенцияләрне үзләштерүендә туган кыенлыкларын билгеләргә мөмкинлек бирәләр. Компетенция булдыруга юнәлдерелгән биремнәрне төрле таратма материаллар рәвешендә дә, төркем

яки индивидуаль эшләтү өчен ныгыту, кабатлау тибындагы дәресләрдә проектор аша күрсәтеп тә үткәрергә мөмкин. Мәсәлән, «Яңгырау һәм саңгырау авазлар»темасын үткәндә, укытучы үз алдына яңгырау һәм саңгырау авазларны аера белү күнекмәләрен булдыруны, аларның аермалыкларын белүне, аваз-хәреф анализы үткәрә белү, авазларга дөрес характеристика бирә белергә өйрәтүне максат итеп куя. Шунлыктан укытучының төп бурычы булып укучыларны яңгырау һәм саңгырау авазларны аерып тора торган билгеләрен күрсәтү һәм практикада куллана белү тора. Бу теманы өйрәнгәндә, мәсәлән, түбәндәге компетенция булдыруга юнәлдерелгән биремнәр тәкъдим итеп була:

1 нче мисал

Стимул:

Сиңа энеңнең өй эшен тикшерергә кирәк. Аңа яңгырау тартыктан башланган сүзләр язып килергә кушылган. Энең җибәргән хатаны тап.

Бирем:

Кайсы рәттә барлык сүзләр дә яңгырау тартыктан башланалар?

1) телефон, каен, сабын

2) балык, дәрес, зурлык

3)китап, гыйнвар, сәгать

4) агач, инә, үрдәк

Җавап бланкы тәкъдим ителә.

Тикшерү инструменты (ачкыч). Ачкычка туры килү — 1 балл, ачкычка туры килмәү — 0 балл.

Биремне үти башлаганчы, укучы башта бирем формулировасын игътибар белән укып чыгарга, тутыру бланкын өйрәнергә тиеш. Эш процессында укучы түбәндәге күнекмәләрне күрсәтергә тиеш:

- авазның яңгырау яки саңгырау аваз булуын таный белү;
- яңгырау һәм тартык авазларны аера белү;
- үзенең карарын дәлилли белү.

2 нче мисал.

Стимул

Син С.Я.Маршакның «12 ай» дигән әкиятен беләсең инде, шулай бит?! Әкияттә үги ана кызны умырзаялар җыеп кайтырга дип урманга куып чыгара. Ул анда 12 айны очрата. ел айлары кызга булышырга уйлаганнар, тик аларның бер шартлары бар: кыз алар кушкан биремне үтәргә тиеш. Кызга булыш әле.

Бирем.

Саңгырау тартыкка тәмамланган ай исемнәрен билгелә.

1. Гыйнвар

2. Февраль
3. Март
4. Апрель
5. Май
6. Июнь
7. Июль
8. Август
9. Сентябрь
10. Октябрь
11. Ноябрь
12. Декабрь

Җавап бланкы:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
		+					+				

Тикшерү инструменты (ачкыч).Ачкычка туры килү – 2 балл, ачкычка туры килмәү – 0 балл.

Орфоэпия өйрәтүдә компетентлы якын килү

Мәктәп курсында укучыларның татар әдәби теленең сөйләм нормаларын үзләштерү каралган. Укучылар мәктәптә орфоэпияне, ягъни дөрес әйтелеш кагыйдәләрен үзләштерергә тиешләр.Белгәнебезчә, авазларны дөрес әйтергә өйрәтү дөрес язарга өйрәтүнең нигезе булып тора.Татар телендә әдәби телдә сөйләшә белү – димәк, татар теле авазларын һәм аваз кушылмаларын дөрес артикулярлаштыру гына түгел, ә бу авазларны үзеңнең һәм башкаларның сөйләмендә аеру күнекмәләре дә ул. Бу эшчәнлек аудированиенең әһәмиятлелеге турында ассызыклый. Дөрес әйтелешне күп тапкырлар тыңлау укучыларга материалны истә калдырырга һәм сөйләмне аңлауга китерә. Әйтелештәге хаталарны барлау максатыннан үз сөйләмеңне тыңлау да бик файдалы. Әйтелеше кыен булган авазларны башта сүз эчендә эшкәртергә кирәк, аннан соң сүзтезмәдә, ә алга таба исә җөмлә эчендә һәм бәйләнешле сөйләмдә. Әйтелеш өстендә эш махсус сайлап алынган күнегүләр өстендә җентекләп уйланылган эшчәнлек булганда гына нәтиҗәле булачак. Мондый төр эшчәнлек «Фонетики һәм орфоэпия» өйрәнгәндә генә түгел, ә тел белеменең башка тармакларын өйрәнгәндә дә үткәрелергә тиеш.

159. **С** **Текстны рольләргә бүленеп, дөрес интонация белән, орфоэпик кагыйдәләрне истә тотып укы. Җөмләләрне укыганда, тавыш хәрәкәтендәге үзгәрешләргә игътибар ит.**

Бакчада бер кыз карандашын югалткан. Бик-бик матур карандаш булган ул үзе.

Аны Заһид тапкан.


— Оһо! Нинди матур! Әй, әй, карагыз әле! Кем карандашын югалтты? — дип кычкырган ул.

Бер малай:

— Бик исең киткән икән. Тапкач, синеке инде ул. Сал кесәңә тизрәк! — дип киңәш биргән.

— Юк, — дигән Заһид, — кесәгә салырга, ул бит минеке түгел. Әни миңа кеше әйберенә тимәскә куша. «Тапкан әйберегезне кешесенә бирегез», — ди минем әнием.

Дәржия Аппаковадан



Татар теле фонетикасы дигәндә, әдәби телдә дөрес сөйләшү дигәндә, без, әлбәттә, авазларны орфоэпик яктан дөрес әйтүне күздә тотабыз. Шунлыктан туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысының бурычы – укучыларның сөйләмнәренә игътибар итеп, ялгышларны даими рәвештә кисәтеп тору. Белгечләрнең тикшерүләреннән күренгәнчә, авазларны дөрес әйтү шәхес булып формалашу өчен зур роль уйный. Сөйләм теле дөрес, аңлаешлы булган балага яшьтәшләре һәм олылар белән контактка керү җиңелрәк. Алар үзләренең фикерләрен һәм теләкләрен дөрес итеп җиткерә беләләр.Ә сөйләм телендә кимчелекләр булган балаларга контактка керү кыенрак. Еш очракта сөйләм үсешендәге кимчелекләр баланың тирә-юньне танып белүенә комачаулый, акыл үсешен тоткарлый.Күзәтүебезчә, мәктәпкә кергәндә, күпчелек балалар сөйләм үсешендә кимчелекләр белән киләләр. Шуңа күрә балаларның сөйләмендәге ул кимчелекләрне тизрәк ачыклап, тәрбия чаралары ярдәмендә төзәтү һәм булдырмый калу өстендә эшләргә кирәк. Моның өчен балалар аваз иҗатына һәм язучыларыбыз әсәрләренә нигезләнеп, авазларның дөрес әйтелешен ныгыту, сүзлек байлыгын арттыру,сөйләм кимчелекләрен төзәтү күнекмәләренә таяну бик әһәмиятле була.Бу максаттан дәреснең билгеле бер этабында (башлангыч мәктәптә) артикуляция гимнастикасын үткәрү уңышлы булачак.

Мәсәләән,

1) [а - о - у - ы]
2) [ә - ө - ү - э - и]
3) [а-ә, о-ө, у-ү, ы-э]
4) [а-а, а-о, а-у, а-ы]
5) [а-а, а-а-о, а-а-о-у, а-а-о-у-ы]
6) [ә-ә, ә-ө, ә-ү, ә-э, ә-и]
7) [ә-ә, ә-ә-ө, ә-ә-ө-ү, ә-ә-ө-ү-и]
8) [а-а, о-а, у-а, ы-а, ә-а, ө-а, ү-а, э-а, и-а]
9) [а-ә, о-ә, у-ә, ы-ә, ә-ә, ө-ә, ү-ә, э-ә, и-ә]
10) [и-ы-э-ә-а-о-ө-у-ү]
11) [ү-у-ө-о-а-ә-э-ы-и]

Орфографик күнегүләр таблицасы

I. Сузык аваз хәрефләре

Ө хәрефе

Бө пө сө зө кө гө тө дө йө нө мө

өч	өй	өр	көз	төн	көт	йөз	сөз	рөхсәт	гөмбә	өрек
өс	өн	өз	көн	көл	сөт	төз	гөл	көрәк	хөрмә	мөмкин

көрәк-көрәкләр	гөмбә-гөмбәләр	көн-көннәр
хөрмә-хөрмәләр	гөл-гөлләр	төн-төннәр

тәмле өрек	матур гөл	ак төннәр тимер көрәк
биш хөрмә	салкын сөт	

Өстәл өстендә өрек, хөрмә бар.
Өй артында дөп-дөп кое казый.(Т.)
Йөгерә-йөгерә йөк ташый.(Т.)
Рөстәм, Зөлфәт, Гөлшат – дуслар.

Авазларны дөрес әйтергә өйрәткәндә халык авыз иҗатыннан (тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар, мәкальләр, һ.б.) файдалану укучыларның грамоталылыкларын үстерүгә һәм камилләштерүгә ярдәм итә.

Тизәйткечләр. Тизәйткечләр әйтү өчен авыр булган, бер-берләренә охшаш сүзләрдән төзеләләр, шуңа карамастан, тизәйткечне бик тиз һәм ялгышмыйча әйтү таләп ителә. Тизәйткечләр, беренчедән, уен-көлке, күңел ачу өчен кулланылсалар, икенчедән, алар сүз һәм иҗекләрне ачык әйтергә,

чиста, дөрес итеп сөйләргә өйрәтәләр. Соңгысына бәйле рәвештә, тизәйткечләрне еш кына **тел төзәткечләр** дип тә йөртәләр.

Кара карга кардан бара
Канатларын кага-кага.
Каркылдый ул:
“Ка-а-ар” да “ка-а-ар!”

Авыр әйтелешле сүзләрдән, сүзтезмәләрдән торган тел шомарту күнекмәсен булдыру — тизәйткечләрнең төп вазифасы. Үзенчәлекле төр буларак, тизәйткечләр 3 төрле орган системасына йогынты ясыйлар: алар артикуляцион ситеманы тонуста тоталар, икенчедән, сулыш алу системасын хәрәкәткә китерәләр, өченчедән, баш мие эшчәнлеген тизәйтәләр.

*Абагага бага-бага, башым бәрдем баганага.
*Вакыт белән акча табыла, акча белән вакыт табылмый.
*Андый төймә Ләбибәдә дә, Нәдифәдә дә бар.
*Оясызны ояга оялатып булмый.
*– Тиз әйт! Тиз әйт! Тизрәк! Тизрәк!
Тиз! Тиз! Тиз! — ди тизәйткеч.
Тизәйкеч ул тиз әйттереп,
Телебезне көйләткеч.
*Тук, тук, тукран, тукылдатып утырам.
Мичтә бәлеш пешә иде, шуны көтеп утырам.
*Кәк-күк, кәк-күк,монда гөмбә бик күп.
Бик күп, бик күп, кәк-күк, кәк-күк.
*Мич башында биш мәче,
Биш мәченең биш башы,
Биш мәченең биш башына
Ишелмәсен мич ташы.
*Кара, кара, кап-кара,
Караган карап кала.
Карамаган карга кебек
*Аттым карга, төште карга,
Карга төште ак карга.
Шул карганы карар өчен
*Шешә белән өч шешә.
Шешә бавын теш чишә.
Шешә чишсәм, теш шешә.
*Күрәсеңме, Гөлчәчәк,
Безнең бакча гел чәчәк.
Уйный анда Гөлчәчәк,
Үскәнгә үлән, чәчәк.

*Сәлим сыерга салам салганда сиксән сигез сәнәк сабын сындырган.
*Саран Сара, саран Сара,
Сарыгына саный-саный
Салам сала саран гына.
Сарыгына саламны да
Санап сала саран Сара.
*Сокланам мин Сабирга,
Сабир сыман сабырга:
Сабирдагы сабырлык
Сабыр хәйран калырлык.
* Бака кебек бак та бак,
Бак та бак килә үрдәк.
Менә шулай була ул
Бакадан алсаң үрнәк.
* Көчле кеше
Очлы шөшле
Белән шушы
Төшне тиште.
* Чүәк чигә чүәкче,
Чүәкчедән күрмәкче,
Чүлмәкче дә чүлмәген
Чүәк кебек чикмәкче.
*Әрәмәдәге әрем әче.
*Башта башлап баскыч башына бас.
*Мин агамның дагаланган атын дагалаганмын.
*Юлга егылгаласам да, елгага егылгалаганым юк.
* Җәйнең ямьле көннәрендә җиләк җыя Җәмилә.
*Үгезегез үзегезнеке, мөгезе үгезегезнеке.
*Без, без, безелдек, без бер рәткә тезелдек.
*Сигез сыер асраганчы, симез сыер асра
*Су буенда була торып, суга сусатмасана.
*Кара карга кардан бара, канатларын кага-кага.
*Кар аттым, кар аттым, ап-ак карны каралттым.
*Күпер башында күп күркә,
* Күп күркәгә кирәк күп көрпә.
*Кара, кара, кап-кара, караган карап кала.
*Таулар биек таллардан, тал бөресе балланган.
*Озын-озын озын юл, озын юлга чыкты ул.
*Казандагы суны кайнарландыралсаң кайнарландыр.
*Чыпчык, чыпчык, чык, чыпчык, чык-чык, кошчык, очып чык!

Санамышлар

*Бер алма, ике алма,өч алма, дүрт алма, биш алма, алты алма, җиде алма, сигез алма,тугыз алма, кызыл алма.
*Әлчи, бәлчи, әни күлмәк үлчи.
Чәүкә, чыпчык, син кал, син чык.
*Әлеш,мәлеш,мичтә бәлеш,
Казанда ит, аша да кит.
*Ак чәйнеккә акча салдым.
– Ничә булды? – Йөз булды.
Әтәлчек,мәтәлчек,
Сиңа туры килде – чык!
*Әке, пәке, кыек сәке.
Майлы ботка, эремчек,
Син калып тор, ә син чык!

Табышмаклар

*“Ач”, — дисәң, ачыла,
“Яп”, — дисәң, ябыла. (А...)
*Ике туган бер-берсен күрмиләр. (К...)
*Бер анадан биш бала. (Б...)
*Бер агачта ике яфрак. (К...)
*Утта янмый, суда батмый. (Б...)
*Җир астында җиз казык. (К...)
*Тәрәзәсе юк, ишеге юк, эче тулы халык. (К...)
* Җәен соры, кышын ак,аңа шулай яхшырак.(К...)
* Агач түгел — яфраклы, тун түгел — тегелгән.(К...)
* Су түгел — сыек, кар түгел — ак. (С...)

Мәкальләр

1.Теле барның иле бар.
2.Тәмле тел — җан азыгы.
3.Иң татлытел — туган тел, анам сөйләп торган тел.
4.Теле барның юлы бар.
5.Тел төмәнгә илтә.
6.Туган телем — иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем.
7.Яхшы сүз балдан татлы.
8.Аз сөйлә, күп эшлә.

9.Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
10.Уку — энә белән кое казу.
11.Калган эшкә кар ява.
12.Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма.
13.Агач җимеше белән, кеше эше белән.
14.Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
15.Ялкаулык-хурлык, тырышлык — зурлык.
16.Җиде кат үлчә, бер кат кис.
17.Ни чәчсәң, шуны урырсың.
18.Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.
19.Кош канаты белән, кеше дуслары белән көчле.
20.Ата — аналы бала — алтын канатлы бала.
21.Әткәй — шикәр, әнкәй — бал.
22.Туган бар җирдә ярдәм бар.
23.Бер рәхмәт мең бәладан коткара.
24.Олыласаң олыны, олылар үзеңне.
25.Телләр белгән — илләр күргән.

«Фонетика, орфография» буенча үтелгәнне кабатлау, белемнәрне тикшерү өчен биремнәр

3 нче бирем. **Бирелгән сүзләрне иҗекләргә бүлегез.**

Балалар, күбәләк, балыкчылар, түземсезлек, уналтынчы, күтәренке, яшьлек, яшелчә, мәсьәлә, мәсәлән, дөнья, кулъюгыч, кулында, тәэсир, үзешчән, үзенчә.

Үрнәк. Балалар — *ба-ла-лар*, ...

4 нче бирем. **Бирелгән сүзләрдә ничә хәреф, ничә аваз бар?**

Яңа, янә, юка, юкә, эш, мәсәлән, мәсьәлә, ядкарь, яткыр, кәгазь, алмаз, тәэмин, элмәк, игълан, суган, якынаю, ерагаю, кыйммәт, кайнар.

Үрнәк. *Яңа* сүзендә 3 хәреф, 4 аваз бар, ...

5 нче бирем. **Хәреф саны белән аваз саны туры килгән сүзләрне беренче, хәреф саны аваз саныннан күбрәк булган сүзләрне икенче, аваз саны хәреф саныннан күбрәк булган сүзләрне өченче баганага язып алыгыз.**

Әни, игълан, яшел, бабай, яшьлек, гарьлек, кулъязма, күндәм, гыйлем, яшәеш, янгыр, кыйммәт, гөлҗимеш, янәшә, мәсьәлә, төзелеш, колын, вәгъдә, яфрак, елан, дәгъва, диңгезче, лачын, нәмәгълүм, юкә.

Үрнәк.

әни	*игълан*	*яшел*

6 нчы бирем. **Калын сузыклардан торган сүзләрне беренче, нечкә сузыклардан торган сүзләрне икенче, калын һәм нечкә сүзыклардан торган сүзләрне өченче баганага языгыз.**

Бурыч, рәхмәт, китап, иман, ярканат, энҗе, нәсел, илһам, озынча, очсыз-кырыйсыз, мәшәкать, нәшриятчы, кузгалак, мәшгульлек, илтифат, пакьлек, нибары, мияубикә, нурланыш, нәкышле, күбәләксыманнар, миһербан, остабикә, рәсүл, рәхим-шәфкать, сау-сәламәт, кыяфәт.

7 нче бирем. **Әйтелешендә сузыклар гармониясе сакланган сүзләрне беренче, сузыклар гармониясе сакланмаган сүзләрне икенче баганага языгыз.**

Табак-савыт, табигать, талиб, такмакчы, тасма, тасмачәчәк, утызменче, ташбака, умарталык, фидакарь, фаҗигале, фикердәш, кодрәт, кардәш, кеше-кара, канәгать, гарәп, кием-салым, гаделлек, каракүл, гадилек, газиз.

Үрнәк.

табак-савыт | табигать

8 нче бирем. **Яңгырау, саңгыраутартыклардан гына, яңгырау һәм саңгырау тартыклардан торган сүзләрне өч баганага аерып языгыз.**

Бала, китап, мәктәп, хөрмәт, уйнап-көлеп, шапшак, язгы, ышкы, инсафлы, зинһар, агай, җилбердәү, хисап, гомер, хәтта, димәк, абыстай, баскыч-баскыч, дөнья, узган-барган, саташу, хат, ефәк, авыз, уйламаганда, елга, сипкеч, төпчек, агай-энелек, урман, тәхет, ипсез, балыкчы, жәлләү, хаста, учак, барабан, ялагайлану, искечә, ерагаю, хуш, галим, башваткыч, тәнәфес.

Үрнәк.

бала | китап | мәктәп

9 нчы бирем. **Яңгырау (саңгырау) тартыклардан гына, яңгырау һәм саңгырау тартыклардан торган кеше исемнәрен өч баганага аерып языгыз.**

Гәдел, Исхак, Марат, Мөршидә, Гали, Такташ, Әлфия, Камил, Ринат, Хатыйп, Роза, Гүзәл, Гата, Тимур, Фәттах, Габдулла, Гыймади, Сафа, Зөлфия, Фәйзи, Җәлил, Әмирхан, Тукай, Исхакый, Әгъләм, Ярулла, Ибраһим, Исәнбәт, Кутуй, Сәхаб, Мирвәли, Мингалим, Фатыйх, Хәким, Гөлбикә, Йөзлебикә, Гәрәй, Галимҗан, Һади, Солтангәрәй, Гөмәр, Чәчәк, Әхмәтһади, Гыйлем, Мөхәммәтҗан.

Үрнәк.

Гадел | Исхак | Марат

10 нчы бирем. **Сүз басымы беренче (икенче, өченче, дүртенче) иҗекләргә төшкән сүзләрне баганалап язып алыгыз.**

Нәрсә, көлә, өченче, авылдашлар, якташларгамы, киләчәкме, баралар, керегез, әнә, барамы, кайталардыр, билгесездер, ишетерләрме, нигәдер, беркемне, көткәнсездер, ишеткәнчә, якташлардыр, белгәнебезчә, кадерсезләмәгез, ишеткәнсездер, татарчалап, килгәнчә, бармагыз, теләмибез, теләгәнчә, сөйләшкәндәй, сөйләшмәгәндәй, күрешербез, кайткалагыз, минемчә, көтмәгәндә, кадерле, яратыгыз.

Үрнәк.

нәрсә | көлә | өченче | авылдашлар

Тулы анализ түбәндәге тәртиптә ясалырга мөмкин:

1) ... (сүз язып куела);
2) хәрефләр: ... ;
3) авазлар; ... :

4) сүздә ... хәреф, ... аваз;
5) хәреф саны белән аваз саны туры килә (туры килми);
6) ... – (калын, нечкә) сузык (-лар);
7) сүзнеңәйтелешендә сузыклар гармониясе (саклана, сакланмый);
8) ... – (парлы, парсыз, яңгырау, саңгырау) тартык (-лар);
9) сүзнеңязылышы әйтелешенә туры килә (туры килми);
10) басым ... иҗеккә төшә.

Шундый тәртиптә эшләнгән фонетик анализ баланыңхәреф-аваз төшенчәсен аңлау яки аңламавын, сүзне дөрес яки ялгыш әйтүен ачыкларга ярдәм итә. Анализ укытучыга баланыңсөйләмендәге һәм язмасындагы ялгышларныңсәбәбен аңларга мөмкинлек бирә.

Укучы, программа таләбе буенча, һәр авазга тулы характеристика да бирә белергә тиеш. Түбәндә сузык һәм тартык авазларга характеристика бирү үрнәкләре тәкъдим ителә.

***11 нче бирем.*Сүзләрнең транскрипциясен языгыз.**

өмет	[	]	корым	[	]
йөреш	[	]	корылма	[	]
көмеш	[	]	кошчылык	[	]
көлке	[	]	торгынлык	[	]
көндез	[	]	торгызу	[	]
бөреләнү	[	]	йомыш	[	]
гөрелте	[	]	болын	[	]
сөремле	[	]	борылыш	[	]
бөрлегән	[	]	шомырт	[	]
бөртекле	[	]	тормыш	[	]
бөтнек	[	]	омтылыш	[	]
төшемле	[	]	токым	[	]
өстенлек	[	]	борыч	[	]
бөркет	[	]	корыч	[	]
чөгендер	[	]	очкын	[	]
урынын	[	]	кереш	[	]
ылыслы	[	]	керемле	[	]
кызыгып	[	]	беренчеләре	[	]
кызыксынырга	[	]	сеңелесен	[	]
кырыгынчы	[	]	күңелдәгесен	[	]

***12 нче бирем*. Күпнокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп языгыз.**

К...з килде... Урман ..ст...ннән й...г..р..п узган алтын б..л...т агачларның яфракларын сары т...скә манды. Усалрак җил искәндә, алар күз яшьләре сыман җир ...ст...нә тамдылар. Куаклардагы чикләвекләр дә тәмам саргаеп җиргә коелдылар. Менә б...рк...нн... ешлык араларын к...мд...р утап чыккандай, урман куелыгы шәрәлеккә ал..ш..нды... Үз...н...ң сары саг...шлары, м...ң карг...шлары белән тулган к...з. Күкләр дә хәзер җәйге к...ннәрдәге к...б...к д...б...рдәп-күкрәп каты итеп яшь коеп еламый, ә тавыш-т...нс...з гына, саб...р карч...клар к...б...к кенә балав...з сыга. (Р.Сибат).

***13 нче бирем*. Сингармонизм законына буйсынган һәм буйсынмыйча килгән сүзләрне аерып төркемләгез.**

Күңелдәгесен, ателье, бертоташтан, балаларыбыздан, көндәлектә, директор, өстәлгә, көлсу, килделәр, барасыңмыни, әйткәләштергәләдем, күзаллау, офис, дусларыбызга, ихата, хөрмәтле.

Файдаланылган әдәбият

1. Гилязова, Л.Г. Дәрестә проблемалы ситуацияләрне куллану / Л.Г. Гилязова, Г.В. Хадиева // Правовые основы функционирования государственных и региональных языков в условиях дву- и многоязычия (мировой опыт реализации языковой политики в федеративных государствах): международная научно-практическая конференция. — Казань: ИЯЛИ, 2021. — 248 с.

2. Гилязова, Л.Г. Туган (татар) тел дәресенең заманча модельләре (белем һәм күнекмәләрне системалаштыру дәресләре) куллану / Л.Г. Гилязова, Г.В. Хадиева // Мәгариф. — 2020. — №2. — Б. 32–33.

3. 5-9 нчы сыйныфларда «Туган тел» предметын яңача укыту. Методик ярдәмлек / М.М.Шәкүрова, Л.М.Гыйниятуллина.– Казан, 2018. – 36 б.

4. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5 нче сыйныф / Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К. Һадиева, Г.В. Һадиева. — Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2017. — 178 б.

5. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында дәүләт теле буларак татар теленә өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр. — Казан: ТР МҮИ, 2021. — 64 б.

6. Фаттахова, Р.Ф. Формирование мотивации у учащихся при обучении татарскому языку / Р.Ф. Фаттахова, Р.Р. Шамсутдинова, Л.Г. Гилязова // Казанская наука. — 2021. — №1. — С.119–121.

7. Формирование универсальных учебных действий в урочной работе: разработка и применение компетентностьно-ориентированных заданий: программа модуля повышения квалификации. — Самара: ООО «Арбат», 2013. — 188 с.